Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы
Усман Әлмеев исемендәге Акъегет гомуми төп белем бирү мәктәбе
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

# “Бакырчы авылы тарихы”

**темасы буенча проект эше.**

Эш авторы: Закирова Раилә IX сыйныф укучысы
Акъегет гомуми төп белем бирү мәктәбе

Җитәкче: тарих укытучысы
Адиятуллина Альбина Рашид кызы

2020 ел

# Эчтәлек

I Кереш.
II Төп өлеш. а) Бакырчының барлыкка килүе һәм кыскача тарихы.
б) Авылыбызның мәгърифәт һәм мәдәният юлы.

III Йомгаклау.

**Максат:**

1. Бакырчы авылы тарихына кагылышлы кайбер тарихи документларга, халыктан язып алынган мәгълуматларга таянып, Бакырчы авылы тарихын яктырту.
2. Югала барган тарихи мәгълуматларны яңарту.
3. “Авыл тарихы” акциясе ярдәмендә эзләнүләр алып барып, авылым тарихын өйрәнү.

**Бурыч:**

Югала барган тарихи мәгълуматларны яңарту, укучылар белән эзләнүләр алып барып, авылым тарихын өйрәнү.

## КЕРЕШ

Туган җир...Туган авыл. Йөрәккә нинди якын, кадерле сүзләр. Безнең һәрберебезнең газиз туган йорты, нигезебез урнашкан кадерле туган авылы бар. Һәр авылның үзенә генә хас кабатланмас, истә кала торган урыннары күп. Кая гына барсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, туган төбәгебезнең гүзәллеген берни дә алыштыра алмый.

Авыллар, авыллар... Аларда безнең үткән тарихыбызның бер өлеше , халыкның моңы, кайгысы-шатлыгы,куанычлары һәм сагышы. Аларның берләре бик борынгы, икенчеләре бик соң барлыкка килгән. Һәрберсенең үз тарихы, үзенең данлыклы кешеләре бар.Авыллар гөрләтеп яшәсә, милләт, халык яшәр, үсәр һәм көчәер.

## ТӨП ӨЛЕШ

Һәр кешенең йөрәгенә якын, җанына җиңеллек бирә торган яраткан урыны була. Минем өчен ул – туган авылым. Минем туган авылым Бакырчы - борынгы авылларның берсе. Туган авылым рәсми рәвештә Бакырчы дип аталса да, халык телендә ул Әрә Бакырчысы дип йөртелә.

Бакырчыбызның 700-800 еллык тарихы барлыгын бөек мәгърифәтче, галим,якташыбыз Каюм Насыйриның "Зөя өязе авыллары буенча" исемле хезмәтеннән беләбез.

Каюм Насыйриның "Зөя өязе" хезмәтеннән күренгәнчә, Бакырчы авылының исеме халыкның бакырчылык белән шөгыльләнүеннән килеп чыккан.

Бакырчыга нигез салган бабайлар урынын бик белеп сайлаганнар. Авылым Укша елгасының ике яры –Үрләч-тау битенә урнашкан.

Авыл халкының төп кәсебе игенчелек һәм терлекчелек була. Авылда кое казучылар да күп була. Авыл халкы шулай ук кирпеч сугу белән шөгыльләнә.

Шулай ук тегермәнчеләр, балта осталары, тимерчеләр, мич чыгаручылар, итекчеләр, мунчала салучылар дә шактый күп була авылда.

Хатын-кызлар буш вакытларында кул белән палас сугу, киндер туку, шәл бәйләү, йон эрләү,сөлге туку һәм чигү эшләре белән даими рәвештә шөгыльләнгәннәр.

XVI гасырда Явыз Иван Казанны алганнан соң, татарларны чукындыру сәясәте алып бара башлый. Мәҗбүри рәвештә татар авылларында бу эш киң җәелеп китә. Безнең авыл да читтә калмый. Документларга күз салыйк.

1897 нче елгы халык санын алу вакыйгасын искә алып китик.1897 елның 29-30 январенда Казан губернаторы А.П.Полторацкой хәрби команда белән өч олау каен чыбыклары төяп, Бакырчыга килә һәм каршылык күрсәтүчеләр шул каен чыбыклары белән суктырылалар. Губернатор үзе бу көннәрдә Акъегеттә тора. Бу вакыйгага багышлап " Бакырчы бәете" чыгарыла.

1927 елдан Норлат районы оештырыла, Бакырчы авылы да Норлат районына керә. Бакырчыда күмәк хуҗалыкка берләшү 1931 елда башлана һәм 1933 елда тәмамлана. Беренче кыр эшләре борынгыдан килгән "Төп алан" басуында башланып китә, шуңа колхозга "Кызыл Алан" исеме бирелә.

Шушы елларда авылыбызда сарык һәм сыер фермалары оештырыла; ат, тавык фермалары төзелә.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Бакырчы авылыннан сугышка 190 лап кеше китә.Сугыштан 80 ләп кеше генә кире әйләнеп кайта.

1958 нче елда өч авыл: Бакырчы,Акъегет,Сүнчәләй авыллары "Киров" исемендәге бер колхозга берләшәләр. 1963 нче елда Норлат районы Яшел Үзән районы составына кертелә һәм барлык колхозлар Яшел Үзән районыныкы булып санала.

1991 нче елда колхоз яңадан өчкә бүленә. Хәзерге вакытта безнең җирләр "Кызыл Шәрыкъ" инвесторлары кул астында.

Бакырчы авылы иң борынгы авылларның берсе булса да, берничә гасырлар дәвамында үзенең тарихын рәсми төстә саклый алмаган. Күп сәбәпләр безнең авыл халкының да мәдәниятен , аның дини үсешен, мәгърифәтчелеген бик нык тоткарлаган.

XIX гасырның ахырында безнең авылда мәгърифәтчелек алга китә башлый. Сабир мулланың тырыш,аңлы хезмәтен халык куәтли: авылда 1890 нчы еллардан соң ике мәчет була. Беренче мәчет: Кизләү өстендә урнашкан була. Анда мулла булып Сабир мулла эшли. Икенче мәчет хәзерге "Яңа мәчет" урынында була. 1941 нче елда аның манарасын төшереп,авыл клубы ясыйлар. Бу мәчет бинасын сүтеп, 1961 нче елда клуб итеп төзелә.

1931-1932 нче елларда атаклы Бакырчы бае – Миңлебай йортында яңа дүртеллык башлангыч мәктәп ачыла һәм бу бина 60 ел буе мәктәп булып хезмәт итә.

1988 нче елда яңа өчьеллык башлангыч мәктәп бинасы төзелә. Ә 1992-1993 нче уку елының 1 нче сентябрендә безнең авылда тулы булмаган урта мәктәп ачыла 1992-2007 нче уку елларында Бакырчы тулы булмаган урта мәктәбе дип йөртелә.

2007-2011 нче елларда мәктәп Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Бакырчы төп гомуми мәктәбе исемендә йөрде. 2012 нче елдан Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Бакырчы башлангыч мәктәп – балалар бакчасы итеп үзгәртелде. Авылыбызның тарихы буларак, мәктәбебездә "Туган якны өйрәнү" музее эшләп килә. Анда авыл халкыннан җыелган бик күп экспонатлар саклана.

Соңгы елларда авылыбызда күп кенә үзгәрешләр булды. Яңа мәдәният йорты, фельдшер-акушерлык пункты ачылды. Былтыр Бахтияров Рафикъ абый бик матур һәм зур итеп "Суфия" мәчетен дә салдырып куйды. Авылыбыз көннән – көн матурая.

Былтыр авылыбыз тарихына багышланган Райхана Зәйнуллинаның "Бакырчымда таңнар ата" дигән китап басылып чыкты.

## ЙОМГАКЛАУ

Мин үземнең авылым белән горурланам . Анда яшәвем белән мин бик шатмын. Мин шушы эзләнү барышында күп кенә материаллардан файдаланып, авыл тарихын күбрәк белдем. Киләчәктә дә авыл тарихын өйрәнүне дәвам итәчәкмен.

Сүземне йомгаклап, шуны әйтәсем килә: без үз Туган авылыбыз тарихын ныграк өйрәнәбез икән, аның киләчәге турында да тирәнрәк уйланырбыз дигән нигез бар. Үткәнебез турында мәгълүматлар табарга, тарихи фактларны ачарга һәркемнең кулыннан килә. Мәктәпләрдә Туган якны өйрәнү эшен тагын да киң җәелдерсәк, әлегә исән булган өлкән яшьтәге кешеләр белән очрашсак, аларның истәлекләрен һәм сөйләгәннәрен язып алсак, Туган ягыбыз безгә үзенең кабатланмас тарихы һәм матур үзенчәлекләре белән тагын да тирәнрәк ачылыр иде. Аны белү, тарихи истәлекләрне бергә туплау, саклау безгә тормышта үз урыны бызны табарга, Ватаныбызга файдалы булып үсәргә ярдәм итәр. Киләчәктә дә тарихлар язылу дәвам итсен, авылларның матурлыгы, кешеләрнең уңган булуы башка буыннарга барып җитсен иде. Чөнки үткәнен белмәгәннең, киләчәге дә юк.

*Чыңлап торган – мәңге тере хәтер,*
*Оныкларга – чал тарихны әйтер...*

Туган авылыма багышланган язмамны укытучы Рәйхана апа Зәйнуллинаның "Бакырчым"дип аталган шигыре белән тәмамларга телим.

Бакырчым

Син ерактан күзгә чалынмыйсың,
Гел оялчан,тыйнак кызлар күк.
Әй,Бакырчым,минем туган җирем
Тирә-якта сиңа тиңнәр юк.

Халкың синең эшчән,эчкерсез,
Мәрхәмәтле тирә-күршеләр.
Туган авылым!Синдә яшәүдән
Олы бәхет бармы кешегә.

Кулланылган әдәбият:

1.К.Насыйри “Зөя өязе”.
2. Загидуллин И.К.”Перепись 1897 года и татары Казанской губернии”.
3. “Татар халык иҗаты” Бәетләр.
4. Зәйнуллина Р. “Бакырчымда таңнар ата”.

**Анкета участника**

| | |
|---|---|
| Ф.И.О. участника | Закирова Раиля Рафиловна |
| Тема исследовательской работы | Бакырчы авылы тарихы |
| Секция | История населенных пунктов (деревень, городов) Горной стороны. |
| Почтовый адрес места жительства участника | 422535, ТР, Зеленодольский район, д.Бакрче, ул.Центральная, д.14 |
| Телефон участника | |
| Адрес электронной почты участника | |
| Ф.И.О. научного руководителя(учителя) | Адиятуллина Альбина Рашидовна |
| Телефон научного руководителя | 89600333328 |
| Название места учебы участника и работы научного руководителя (общеобразовательного учреждения) | МБОУ «Акзегитовская основная общеобразовательная школа имени Усмана Альмеева Зеленодольского муниципального района Республики Татарстан". |
| Почтовый адрес общеобразовательного учреждения | **422535, РТ, Зеленодольский район, с. Акзигитово, ул. Центральная, д. 7** |